КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 декабрь г.Казань № 1117

«Лаеш» индустриаль паркы идарәче компаниясенең – «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Индустриаль парклар, сәнәгать технопарклары һәм югары технологияләр өлкәсендәге технопарклар, махсус икътисадый зоналар инфраструктурасы объектларын төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү чыгымнарын каплауга субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме алуга хокуклы Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу турында» 2014 елның 30 октябрендәге 1119 номерлы, «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Лаеш» индустриаль паркы идарәче компаниясенең – «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең Россия кредит

оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин